| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.08.2022 Баулы шәһәре № 118

2016-2021 елларга һәм 2030
елга кадәр план чорына Баулы
муниципаль районының
социаль-икътисадый үсеш
тратегиясенә үзгәрешләр
кертү турында

Башкарма комитет җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасары Э.И. Галимовның «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нәтиҗәләре турында» докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Башкарма комитет җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасары Э.И. Галимовның «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нәтиҗәләре турында» мәгълүматын исәпкә алырга;

2. Баулы муниципаль районы Советының 2016 елның 5 сентябрендәге 77нче карары белән расланган (2019 елның 16 октябрендәге 220 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 15 нче «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр план чорына Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый

үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары комплексы» таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бәян итәргә: www:pravo.tatarstan.ru һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында www:Bavly.tatarstan.ru закон белән билгеләнгән вакытта.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы урынбасары,
район Советы рәисе урынбасары Р.Г. Хәмидуллин